**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

12.11.2015 Яр Чаллы № 3326

«2016-2018 елларга Тукай муниципаль районында
хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту
буенча программа»ны раслау турында

«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2016-2018 елларга Тукай муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча программа»ны кушымта нигезендә расларга.
2. Милек формасына бәйсез рәвештә, оешма, учреждение, предприятие җитәкчеләренә әлеге программаны гамәлгә ашыру буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә.
3. Хезмәтне саклау буенча Координация советына предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә хезмәтне саклау торышын контрольдә тотуны тәэмин итү буенча максатчан эш алып барырга, аларга кирәкле методик ярдәм күрсәтергә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча беренче урынбасары Р.Т. Гыйзатуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчес Р.В. Асылгәрәев